КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 13 май г.Казань № 589

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 20 август, 756 нчы карары белән расланган Яшьләр сәясәте, иреклелек (волонтерлык), яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирү һәм хәрби хезмәткә чакырылыр алдыннан аларны хәрби хезмәт үтүгә әзерләү өлкәсендәге чараларны һәм яшьләр өчен социаль юнәлештәге башка чараларны оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яшьләр сәясәте, иреклелек (волонтерлык), яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирү һәм хәрби хезмәткә чакырылыр алдыннан аларны хәрби хезмәт үтүгә әзерләү өлкәсендәге чараларны һәм яшьләр өчен социаль юнәлештәге башка чараларны оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 20 август, 756 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 15 июнь, 558 нче; 2023 ел, 6 февраль, 107 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Яшьләр сәясәте, иреклелек (волонтерлык), яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирү һәм хәрби хезмәткә чакырылыр алдыннан аларны хәрби хезмәт үтүгә әзерләү өлкәсендәге чараларны һәм яшьләр өчен социаль юнәлештәге башка чараларны оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле

чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2025 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары белән расланган «2015 – 2025 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасы.»;

9 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2023 елда «100 лидер – киләчәк Татарстан. Цифрлаштыру. Тотрыклы үсеш» республика чарасында җиңүчеләргә акчалата бүләкләү түләү.»;

12 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда катнашучы чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

13 пунктның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чыгымнарны каплауга субсидия биргәндә – чара буенча фактта башкарылган чыгымнарны раслый торган документлар.»;

19 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«монда $З_1$, $З_2$, $З_3$, ..., $З_n$ – әлеге Тәртипнең 9 пунктындагы икенче – егерменче абзацларында күрсәтелгән юнәлешләр буенча финанс белән тәэмин итү (каплау) чыганагы субсидия булган расходлар (чыгымнар).»;

түбәндәге эчтәлекле $19^1$ пункт өстәргә:

«$19^1$. «100 лидер – киләчәк Татарстан. Цифрлаштыру. Тотрыклы үсеш» республика чарасын үткәрү чыгымнарын каплау максаты белән субсидия күләме (S) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = (З_1 + З_2 + З_3 + ... + З_n) + (М_1 \times М_2),$$

монда:

$З_1$, $З_2$, $З_3$, ..., $З_n$ – әлеге Тәртипнең 9 пунктындагы икенче – егерме беренче абзацларында күрсәтелгән юнәлешләр буенча каплау өчен субсидия бирелә торган чыгымнар;

$M_1$ – «100 лидер – киләчәк Татарстан. Цифрлаштыру. Тотрыклы үсеш» республика чарасында җиңүчеләрнең 5кә тигез булган саны;

$M_2$ – 2023 елда «100 лидер – киләчәк Татарстан. Цифрлаштыру. Тотрыклы үсеш» республика чарасында җиңүчегә 100,0 мең сум күләмендә акчалата бүләкләү күләме.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин